| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЧИСТОПОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

***Постановление*** ***Карар***

**2022 елның 22 апреле** **Чистай шәһәре** **№ 293**

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июнендәге 363 номерлы карары белән расланган бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына Чистай шәһәр прокуратурасының 2022 елның 15 апрелендәге 02-08-01-2022 номерлы протестын карап, норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июнендәге 363 номерлы карары белән расланган бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендәге 2.8.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 8 пунктча өстәргә:

«8) су басу зонасы чикләрендә урнашкан җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыру (бакча йортын торак йорт дип тану турында гаризаны карагандa)»;

1.2. «2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 2.8.7 пунктча өстәргә:

« 2.8.7. Бакча йортын торак йорт яисә торак йортны бакча йорты дип танудан баш тарту турындагы карар мөрәҗәгать итүчегә мондый карар кабул ителгән көннән 3 эш көненнән дә соңга калмыйча бирелә һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов